

# Иҗади сәхифә

**май, 2023**

Сәхифәне оештыручылар: 3 нче мәктәпнең татар теле
һәм әдәбияты укытучылары методик берләшмәсе

ГОД ПЕДАГОГА И НАСТАВНИКА

2023

УКЫТУЧЫЛАР ҺӘМ ОСТАЗЛАР ЕЛЫ

2023 нче ел – укытучылар һәм остазлар елы. Дөньядагы күп кеше үз укытучыларын хөрмәткә лаеклы дип саный, шуңа да бу ел остазларны искә алу , аларның дәрәҗәләрен күтәрү өчен билгеләп үтелә.

Безнең Минзәлә шәһәре 3 нче санлы урта мәктәбендә 5 татар теле һәм әдәбияты укытучысы эшли. Барысы да дәрәҗәле, зур уңышларга ирешкән укытучылар. Эш стажлары да бик зур. Шул укытучыларның берсе – Альбина Миңлегол кызы Гарфеева. Альбина Миңлегол кызы бик тырыш, таләпчән укытучы, аны укучылары бик яраталар, ә укытучылар аның белән еш кына киңәшләшәләр. Ул хезмәт юлын башка милләт укучыларын татар теленә өйрәтүгә багышлаган остаз. Дәресләре һәрвакыт бик кызыклы, эчтәлекле, шул ук вакытта укучыларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән. Аның укучылары бик күп төрле республика һәм район күләмендә үткәрелгән бәйгеләрдә катнашалар, призлы урыннарга лаек булалар. Альбина Миңлегол кызы әти-әниләр өчен дә үрнәк укытучы, аны укучылар да, укытучылар да, әти-әниләр дә хөрмәт итәләр, рәхмәтләрен әйтәләр.



Татар балаларына 30 елдан артык белем биргән икенче укытучыбыз – бу Шәйхетденова Алфира Сергей кызы. Аның дәресләрендә укучылар татар теле кагыйдәләреннән тыш татар язучыларының иҗатлары белән танышалар, әдәби татар телендә сөйләшергә өйрәнәләр. Әдәп кагыйдәләре, телне хөрмәтләү, туган илне яратырга өндәү - Алфира Сергей кызының төп бурычы булып кала. Татар телен камил белеп, үз укучыларыннан да шуны таләп иткән укытучы ул!

Үз укучыларын төрле республика һәм район бәйгеләрендә катнаштырып, зур уңышларга ирештергән укытучы ул. Шәйхетденова А.С. укучыларның яраткан укытучылары булып кала.



Менә шундый тырыш укытучылар булганда гына, татар телебезнең яшәве дәвам итәр, укучылар матур итеп татарча сөйләшергә өйрәнерләр һәм үз милләтләренең чын вәкилләре була алыр дип ышанып каласы килә...

«Боекмас өчен күңелләр, кимсенмәс өчен йөрәк – сез кирәк, укытучылар, безгә һәрчак сез кирәк!» диясе генә кала...

## 2022-2023нче уку елында мәктәбебезнең укучылары төрле бәйгеләрдә актив катнаштылар.

Җәләева Азалия, Гыйләҗева Ралина – туган телләр елына багышланган бәйгедә номинациядә җиңүчеләр;

“Тукай рухы күңелләрдә” бәйгесендә номинациядә җиңүчеләр;

I Республика “Кызыл ромашка” бәйгесендә Волоскова Дарья 1нче дәрәҗәдәге лауреат;

“Без бергә “ республика бәйгесенең муниципаль этабындаГайсина Ралинә 3нче дәрәҗәдәге лауреат;

М.Җәлил туган көненә багышланган “Тормышым җыр булып яңгырады” район бәйгесендә Сәхәпова Мәрьям җиңүче дипломы;

“Традиции живая нить» бәйгесендә Гыйләҗева Ралинә 3 нче урын;

II Бөтенрәсәй Халыкара “Моабит дәфтәре” бәйгесендә Iнче дәрәҗәдәге лауреат (Гатина Алсу, Җәләева Азалия Симанова Анна, Назарова София);

II Республика шигырь сөйләүчеләр бәйгесендә 1нче һәм 2 нче дәрәҗәдәге лауреатлар Шварцман Дамир һәм Ханипова Екатерина;

VII республика «Тукай һәм Пушкин йолдызлыгында» бәйгесендә Шварцман Дамир 2нче дәрәҗәдәге лауреат;

Бөтенрәсәй “Сихри сандык” иҗади уенында диплом (Коротина Кристина, Лисунова Софья, Жарова Юлиана, Хаматдинов Шамиль, Вафин Вячеслав, Федотов Дамир);

Республика этабының “Без бергә” балалар фестиваленең муниципаль этабында «Дуслык” фольклор ансамбле 2 нче дәрәҗәдәге диплом һәм Гайсина Ралинә 3 нче дәрәҗәдәге лауреат булдылар.

### “Сәләт” театр түгәрәге эшчәнлеге.

Мәктәбебезнең татар теле һәм әдәбияты укытучылары җитәкчелегендә мәктәптә күп спектакльләр куела. Ел саен укучыларыбыз, аеруча төрле милләт балалары, сәхнә әсәрләрендә уйныйлар. Спектакльләр ике телдә әзерләнә, укучылар бу телләр аша осталыкларын күрсәтәләр.

VII республика “А.С.Пушкин һәм Г.Тукай һолдызлыгында” иҗади бәйгесендә түгәрәккә йөрүче укучылар 3нче дәрәҗәдәге дипломга лаек булдылар.

“Бөек Җиңүнең яшь геройлары” дип исемләнгән республика бәйгесенең муниципаль этабында катнашып, 1 нче дәрәҗәдәге дипломны алдылар.

Яшьләр театрлары фестиваленең муниципаль этабында катнашып, 2 нче дәрәҗәдәге диплом белән бүләкләнделәр һәм республика этабында да чыгыш ясадылар.










II Всероссийский межнациональный конкурс чтецов и вокалистов в честь 117-летия Героя Советского Союза Мусы Джалиля
Моабитская тетрадь
Диплом
Лауреата 1 степени
награждается
Театральный коллектив "Сәләт"
Гатина Алсу Ринатовна,
Залеева Азалия Ильфатовна,
Назарова София Михайловна,
Симанова Анна Дмитриевна,
Шагапова Софья Эдуардовна,
Хамзина Варвара Кирилловна,
Киракосян Лариса Якобовна,
ХаматдиноваАлина Айратовна
Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Средняя общеобразовательная школа №3» г.Мензелинска РТ
руководители Залеева Гульгена Галимзяновна, Тимиркаева Ольга Анатольевна
номинация "Художественное чтение"
Волгоград 2023

## “Укытучының функциональ грамоталылыгы –укучының функциональ грамоталылыгы үсү нигезе”

Район семинары булып узды. Анда төрле мәктәпләрдән татар теле һәм әдәбияты укытучылары катнашты. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары Гарфеева Альбина Миңлегол кызы һәм Тимиркаева Ольга Анатолий кызы үзләренең мастер-классларын күрсәттеләр. Алар 9нчы сыйныф өчен “Мәгубә Сыртланова” темасы буенча дәрес этапларының ике өлешен күрсәттеләр.





Ел дәвамында мәктәптә укучылар өчен төрле чаралар үткәрелде. Бу – КВНнар, Г.Тукай һәм М.Җәлил иҗатына багышланган чаралар, Туган телләр көне, “Сәләтле укучы” бәйгесе, караган кинофильм буенча әңгәмәләр, “Әниләр бәйрәме”, “Кызыклы татар теле” һ.б. Бу бәйгеләрдә укучылар татар теле дәресләрендә алган белемнәрен күрсәтәләр, аны актив сөйләмгә кертергә тырышалар һәм диалогик сөйләм телен үстерәләр. Шулай ук үз белемнәрен, зирәклекләрен ачалар.





## Проект эшчәнлеге.

Татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә укучылар төрле проект эшләре башкаралар, аларның темалары төрле була, ә иң нәтиҗәлесе мартта үтә. Проект эшләрен 5-9 нчы сыйныф укучылары башкара (5-8 нче сыйныфлар – төркем белән, ә 9 нчы сыйныф укучылары – шәхси).

Татар теле һәм әдәбияты методик берләшмәсендә барлыгы 18 проект эше яклянды, шуларның 8е төркемдә эшләнде, 10 укучы шәхси проект иде.

Укучылар татарча сөйләргә тырыштылар, Укучылар предмет нәтиҗәләрен күрсәттеләр, регулятив уку гамәлләре күбесенең уртача дәрәҗәдә. Иң яхшы проектлар: “Татар телендә сингfрмонизм законнары” һәм “Габдулла Тукайның экият геройлары”. Бу ике проектның җитәкчеләре Әхмәтшина Л.М. һәм Гарфеева А.М.

Ә кыска дәвамлы проектларның темалары “Татарстан”, “Әнием”, “Мин яшәгән шәһәр”, “Минем дустым” һ.б. Мондый проект эшләрен укучылар дәрес вакытында дә эшләп бетерә алалар, чөнки аларның күләме зур булмый.

Проект эшчәнлеге өстендә эш ел саен дәвам итәчәк, чөнки бу Федераль дәүләт белем биру стандартларына кертелгән.



***“Белем тәҗрибәдән туа”***

*татар халык мәкале*



## “Татарча диктант”

Мәктәптә “Татарча диктант”та катнашучылар саны елдан ел арта. Укучылар белән беррәттән укытучылар да үз белемнәрен сыныйлар.

***********************************

## “Көмеш кыңгырау” газетасында язмалар

3нче сыйныф укучылары үзләренең язмаларын республика газетасында бастырдылар. Алар үзләренең әниләре турында яздылар. Һәр бала әниләре турында йөрәктән чыккан уй-фикерләрен җиткерделәр һәм бу хикәяләр басылып чыкты.

4 нче сыйныф укучылары Галимарданова Яна һәм Минлибаева Дарина әниләренә ярдәм итү турында яздылар.

## “Сабантуй” бәйрәме

Башлангыч сыйныф укучылары өчен Сабантуй бәйрәме үткәрелде. Анда төрле милли уеннарда көч сынаштылар.

## “Су анасы” фильмы

Укучыларга “Су анасы” фильмы күрсәтелде. Ул Г.Тукай сюжеты буенча үзгәртелеп, яңача төшерелгән.

## Рәшит Гәрәй исемендәге китапханәгә сәяхәт

5 нче В сыйныфы укучылары Рәшит Гәрәй исемендәге китапханәдә кунакта булдылар.Китапханәчеләр алар алдында чыгыш ясадылар, шулай ук күргәзмә белән таныштылар һәм тематик уеннар уйнадылар

## Бөтенрәсәй олимпиадасының муниципаль этабы

Укучылар башка фәннәр белән беррәттән татар теле һәм әдәбиятыннан олимпиадада катнашалар. Укытучылар ел буена бу сәләтле укучыларны әзерлиләр. Быел да олимпиадада катнашучыларыбыз булды һәм нәтиҗәләре шундый:

татар балалары арасында

Гатина Алсу 7нче а сыйныфыннан призер;

Залеева Азалия 8 нче а сыйныфыннан призер;

Ханова Әдилә 6 нчы б сыйныфыннан призер

(укытучылары Шайхутденова Ә.С.);

рус төркемендә укучы балалар арасында

Аксенова Эсмира 8 нче в сыйныфыннан җиңүче (укытучысы Җәләева Г.Г.)

Мерзлякова Эвелина 6нчы в сыйныфыннан призер (укытучысы Әхмәтшина Л.М.)

Вафина Виктория 9нчы а сыйныфыннан җиңүче (укытучысы Тимиркаева О.А.).

Укучыларга алдагы уку елында да уңышлар телибез.

***

Татар теле һәм әдәбияты укытучылары үзләре дә төрле бәйгеләрдә, конференцияләрдә актив катнашалар.

Әхмәтшина Лариса Михайловна “Татар теле һәм әдәбияты укытучысының эффектив формалары һәм методлары” темасына региональ семинар- практикумында чыгыш ясады, төрле акцияләрдә актив катнашты.

Тимиркаева Ольга Анатолий кызы Гыйлфанов Фәнис исемендәге IV зона фәнни-гамәли конференциясендә катнашып, “Иң яхшы мастер-класс” номинациясендә 2 нче урынны яулады.